Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Светлоозерского
сельского поселения Заинского
муниципального района

ул. Фардеева, д.15, с. Светлое Озеро,
Заинский район, 423538

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Якты Күл авыл җирлегенең
башкарма комитеты

Фардеев урамы, 15нче йорт, Якты
Күл авылы, Зәй районы, 423538

Телефон, факс 68-2-88. Электронный адрес: Svoz.Zai@tatar.ru, сайт:
http://zainsk.tatarstan.ru/rus/svetloozerskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«14» март 2019 ел.** **№ 3**

**Якты Күл авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә координация яки киңәшмә органнарын төзү тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында" 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге Уставы нигезендә

**карар бирәм :**

1. Якты Күл авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә координация яисә киңәшмә органнарын төзү тәртибен расларга ( кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга, (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
http://zainsk.tatarstan.ru/rus/svetloozerskoe.htm

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **З.З.Мухтаров**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Якты Күл авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2019 елның
14 мартындагы 3 номерлы карарына
1 нче кушымта

# Якты Күл авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә координация яисә киңәшмә органнарын төзү ТӘРТИБЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә координация яки киңәшмә органнары (алга таба - Координация органнары) Якты Күл авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыру буенча килешенгән гамәлләрне тәэмин итү максатларында оештырыла.

Координация органнары билгеле бер мәсьәләләрне хәл иткәндә яисә конкрет чаралар үткәргәндә кече һәм урта эшмәкәрлекне субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыручы җирле үзидарә органнары яисә коммерциячел булмаган оешмалар инициативасы буенча булдырылырга мөмкин.
Киңәшмә органнары Советлар дип аталалар һәм тәкъдим итү характерында булган мәсьәләләрне алдан карау һәм алар буенча тәкъдимнәр әзерләү өчен төзелә.

Төзелә торган совет яки комиссия бер үк вакытта координация органы да, киңәшмә органы да була ала.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыра торган коммерциячел булмаган оешмалар координация органы төзү турында мөрәҗәгать иткән очракта, җирле үзидарә органнары бер ай эчендә мондый коммерцияле булмаган оешмаларга кабул ителгән карар турында хәбәр итә.
Координация органнары төзү өчен Якты Күл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге администрациясе күрсәтелгән нигезләмә проектын эшли:
* орган исеме һәм аны оештыруның максаты;
* рәис, рәис урынбасары, җаваплы сәркатиб вазыйфасы билгеләнә;
* Координация органнарының персональ составы билгеләнә;
* Координация органнары рәисе һәм җаваплы секретаре вәкаләтләре күрсәтелә;
* кирәк булганда Координация органнарын булдыру максатына ирешүне тәэмин итә торган башка нигезләмәләр кертелә;
нигезләмә Якты Күл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге администрациясе карары белән раслана;
* Координация органнарын төзү турындагы карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.
Координация органнары үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты Указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы законнарына, башка норматив хокукый документларга, шулай ук әлеге Тәртипкә таяна.

**2. Координация һәм киңәшмә органнарының төп максатлары**

Координация һәм киңәшмә органнары максатларыннан чыгып оештырыла:

1. Якты Күл авыл җирлегенең социаль-икътисади үсешендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының ролен арттыру;
2. Җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары һәм эшмәкәрлек субъектлары, иҗтимагый берләшмәләр һәм кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмалар белән эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыру .
3. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә муниципаль сәясәтне эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга җәлеп итү;
4. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының проблемаларын тикшерү һәм гомумиләштерү, аларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау;
5. Җәмәгать оешмаларын, эшмәкәрләрне, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен гражданнарның эшкуарлык эшчәнлегенә хокукларын гамәлгә ашыруга кагылышлы мәсьәләләр буенча фикер алышуга җәлеп итү һәм әлеге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр әзерләү;
6. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән инициативаларны күрсәтү һәм аларга ярдәм итү;
7. Кече һәм урта эшмәкәрлек үсешен җайга сала торган муниципаль хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү турында;
8. Якты Күл авыл җирлеге администрациясе тарафыннан билгеләнә торган башка максатларда.

**3. Координация һәм киңәшмә органнары составы**

Координация яки киңәшмә органнары составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыручы коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре, кече һәм урта бизнес вәкилләре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре килешенеп керә ала.

Координация яки киңәшмә органының персональ составы һәм вәкаләтләре Якты Күл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге администрациясе карары белән раслана. Координация яки киңәшмә органы рәисе - Якты Күл авыл җирлеге хакимияте башлыгы.

**4. Координация һәм киңәшмә органнары эшчәнлеген тәэмин итү**

Координация яки киңәшмә органы, әгәр аның утырышында аның әгъзаларының илле проценты катнашса, хокуклы була. Карала торган

мәсьәлә буенча карар утырышта катнашучы Координация яки киңәшмә органы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Координация яки киңәшмә органы эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Якты Күл авыл җирлеге администрациясе тарафыннан гамәлгә ашырыла, аның белән тиешле Координация яки киңәшмә органы булдырылган.

Координация яки киңәшмә органының эш регламенты аның утырышында раслана.